

2023 елнын 17 маенда «Педагог 13. ру» мәйданчыгында туган тел укытучылары (мокша, әрзә, татар), мордва һәм татар язучы-фронтовиклары истәлегенә багышланган «Алар Ватан очен сугыштылар» тобәкара фәнни-гамәли конференциясе узган. Конференция эшендә Мордовия һәм Татарстан республикалары, Пенза, Ульяновск, Ырымбур олкәләре мәгариф оешмаларынын педагогик хезмәткәрләре катнашкан. Барлыгы 35тән артык педагог бу конференция эшендә катнашкан.      Конференциядә катнашучыларга сәламләv сvзе белән Самсонова Татьяна Васильевна, «Педагог 13. ру» ректоры морәҗәгать иткән. Ул билгеләп vткәнчә, һәр гаиләдә Ватан очен алгы сызыкта батырларча сугышкан, кон-тон тылда фидакарьлек белән эшләгән, фронтка ярдәм иткән, илне жимерекләрдән торгызган кешеләр турында истәлекләр изге итеп хормәт ителә. Безнен ветераннар, укытучылар, язучылар һәм шагыйрьләр илебезне яклап батырларча сугыштылар. Алар - безнен әхлакый ориентирыбыз, патриотизм һәм Ватанга тугрылык vрнәге, ди.

Конференциянен модераторы булып В.Ф. Рогожина, югарыда әйтелгән «Педагог 13. ру» учреждениянен этномәдәни белем бирv лабораториясе модире чыккан һәм ул чыгыш та ясаган. В.Ф. Рогожина ассызыклаганча, Жинvгә ышану, дошманга нәфрәт рус, мордва, татар шагыйрьләре һәм язучыларынын хәрби әсәрләренен топ темасы. Мәктәп программасына кертелгән һәр әдәбият әсәре укучынын әхлакый vсеше һәм шәхесне патриотик тәрбияләv очен яхшы материал бирә.

Конференциядә Мордовиянен татар милли мәктәпләрендә хезмәт итеп киләчәк буынга белем, тәрбия биреп килгән укытучылар да эш тәжрибәләре белән уртаклашканнар. Алар – Ләмберә районы Пензятка урта мәктәбе укытучысы Равза Мокаддәс кызы Юмаева, шул ук районнан Черемиш топ мәктәбе укытучысы Фазия Фәрит кызы Боярова, Рузаевка районы Болдово урта мәктәбе укытучысы Наилә Идрис кызы Башмакова, Кадошкино районы Латышовка урта мәктәбе укытучысы Светлана Равиль кызы Поташова, шул ук районнын Большие Поляны топ мәктәбе директоры Светлана Наиль кызы Кильдеева һәм кинәшчесе Зәйнәб Хосәен кызы Кильдеева. Тобәкара фәнни-гамәли конференциядә катнашучылар әхлакый-патриотик тәрбиядә олкәннәр, бигрәк тә якын кешеләр vрнәге зур әһәмияткә ия дигән фикергә килделәр. Гаиләнен олкән әгъзалары, Боек Ватан сугышында катнашучылар, аларнын фронт һәм хезмәт батырлык-лары тормышыннан алынган конкрет фактларда балаларга «Ватан алдындагы бурыч», «Ватанга мәхәббәт» кебек моһим тошенчәләрне сендерергә кирәк, диделәр. Тобәкара конференция кысаларында «Искерv срогы булмаган» Ботенроссия тикшеренv проект эшләре конкурсынын тобәк этабы жинvчеләрен һәм призерларын бvләкләv дә булды.

**Наилә НАСЫРОВА**